Чыганак: Мәгариф. - 2012. - № 9. - С. 54-56

**2012 ЕЛ — ТАТАРСТАННЫҢ ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАСЫ ЕЛЫ**

# ТУГАН ЯГЫБЫЗ ТАРИХЫН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**Ринат ХӘЙРУЛЛИН, Мамадыш районы Урта Кирмән урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы**

**Иң яраткан язучыларымның берсе — Василий Шукшин. Әле шушы араларда гына аның «Печки-лавочки» дигән повестен яңадан укып чыктым. Профессор Сергей Федоровичның улы Иван, шулай ук галим кеше, болай ди: «Минем үз ихтыярымда булса, мәктәпләрдә ир-ат укытучыларның санын арттырыр идем». Моннан ярты гасыр элек язылган сүзләр никадәр заманча яңгырый! Кызганыч, әлбәттә. Бүгенге мәктәп шартларында укучыларга аң-белем һәм тәрбия бирергә тәвәккәллек кылган укытучылар алдында җәмгыятебез һаман да бурычлы булып кала. Безнең ихтыярда түгел шул...**

**Күңелемдә мондый уйлар Ринат Хәйруллинның «Мәгариф» журналы редакциясенә юллаган яңа мәкаләсен укыгач туды. Иң актив авторларыбызның берсе ул. Казанда да, Кирмәнчек шәһәрлегендәге археологик казу эшләре вакытында да үзе белән шактый аралашканым бар. Аңа симпатиям зур. Ул гел үзе кебек тыйнак-тәртипле, җор телле укучылары белән булыр. Аларның мең төрле сорауларыннан бер дә туймас, шуклыкларын, җиңелчә генә тәртип бозып куюларын гафу итә белер.**

**Беркадәр вакыт мәктәптә укытып алган кеше буларак, мин шундый фикергә килдем: яхшы укытучы булу, тәптәнрәк уйласаң, бик җиңел икән. Моның өчен бары тик укучыларны үз балаларыны яраткан кебек яратырга, укыта торган фәнеңне тирән белергә һәм ... бераз артистлык сыйфатларына ия булырга гына кирәк. Минем хөрмәтле тарихчы коллегам Ринат Миңлегаян улы әлеге таләпләрнең барысына да җавап бирә, милли җанлы, новатор укытучыларга хас барлык күркәм сыйфатлар да хас аңа.**

**Р.Хәйруллинның соңгы елларда «Мәгариф»тә дөнья күргән мәкаләләрен кабат күздән кичердем. Туган ягыбыз тарихына багышланганнары бар, балалар белән дәрестән тыш үткәрелә чаралар, аерым темаларга багышланган дәрес үрнәкләре... Аның 2007 елда Мәгарифне үстерү институты тарафыннан нәшер ителгән «Гасырларга илтер тарихым бар» дигән методик кулланмасын да республикабыз укытучылары үз эшләрендә бик теләп куллана. Әйе, күп укый, күп белә, фикерләрен кәгазь битенә матур итеп төшерә алырлык сәләте бар. *(Юкка гына ул Россия һәм Татарстан Журналистлар берлекләрендә әгъза булып тормый торгандыр.)* Интернет сайтында мәгариф өлкәсендәге үзгәртеп коруларга карата да үзенең кыю фикерләрен җиткерергә вакыт таба. «Булдырасың, егет!» — дип, ихластан мактыйсы килә үзен.**

**Тарих җене кагылган егетебез 24 сентябрьдә үзенең олуг юбилеен каршыларга җыена. Ринат Хәйруллинга — 50 яшь! Шул уңайдан аны «Мәгариф» журналының барлык укучылары, мөгаллимнәр исеменнән гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез, изге хезмәтендә яңадан-яңа иҗади уңышлар, исәнлек-саулык, гаилә бәхете телибез.**

**Фаяз ХУҖИН, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор.**



Тарих фәнен укытудагы төп проблемаларның берсе — материалның күплеге, ә бирелгән сәгатьләр санының азлыгыдыр, минемчә. Бу — бигрәк тә чыгарылыш сыйныфларда сизелә. Кайбер материалны дәрестә биреп тә бетереп булмаска мөмкин. Мондый очракта укытучыга дәрестән тыш чаралар ярдәмгә килә.

Һәр уку елында мәктәбебездә тарих атналыгы уза. Әлеге чарага укытучы да, укучылар да ныклап әзерләнә. Атнаның һәр көнендә укучыларны җәлеп итәрлек, аларга файдалы булырлык чаралар үткәрүне планлаштырабыз. Шундый чараларның берсен — ярдәмчел тарихи дисциплиналарга багышланганын журнал укучылар хөкеменә дә тәкъдим итәм.

**Максат.** Укучыларда ярдәмче тарихи дисциплиналар һәм дөрес тарихи мәгълүмат алуда аларның роле турында күзаллау булдыру. Аларның тарихи дисциплиналар белән кызыксынуларын арттыру, предмет буенча укучыларның белем һәм күнекмәләрен активлаштыру; логик фикерләү, күзаллау, проблемалы мәсьәләләр чишү, тарихи чыганаклар белән эшләү күнекмәләрен үстерү, үз Ватанының тарихи узганына, кешелекнең мәдәни мирасына хөрмәт белән карау тәрбияләү.

**Кичә барышы.**

**Укытучы.** Галимнәр кешелек җәмгыятенең меңнәрчә елларга сузылган озын-озак тарихын өйрәнгәндә тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итә. Тарихи чыганаклар бик күп төрле була. Галимнәр аларны төп ике төргә бүлеп йөртә: **язма чыганаклар** һәм **матди чыганаклар.** Язма чыганакларга дәүләт архивларында саклана торган рәсми документлар, борынгы кульязмалар, тарихи шәхесләр тарафыннан язылган истәлекләр һ.б. керә. Матди чыганакларны археология фәне өйрәнә. Болар: борынгы һәм урта гасырлар чорына караган авыл һәм шәһәр хәрабәләре, торак йорт урыннары, хуҗалык корылмалары, һөнәрчелек остаханәләре, борынгы зиратлар һ.б. Болардан тыш та бик күп тарихи чыганаклар бар. Мәсәлән, халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә (әкиятләр, табышмак-мәкальләр, риваять-легендалар, бәетләр) тарихи вакыйгалар, фактлар чагыла. Ә туган ягыбызның тарихын өйрәнгәндә без

топонимнарга — төрле географик атамаларга мөрәҗәгать итәбез. Тарихи чыганакларны дөрес итеп туплау, фәнни нигездә аңлату өчен ярдәмче тарихи дисциплиналар бирә торган махсус белемнәр кирәк. Бу дисциплиналарның кайберләрен схемада күрсәтик:




Аларның һәркайсының үз тикшеренү өлкәсе бар. Әйдәгез, алар белән якыннанрак танышыйк.

**Палеография** — кульязма һәм басма чыганакларның тышкы билгеләрен, язу материалын, хәрефләр язылышын, сәнгати бизәлешен; **хронология** — вакыйгалар эзлеклелеген; **метрология** төрле чорлардагы озынлык, авырлык, мәйдан, күләм үлчәү алымнарын, аларның бүгенге үлчәү системасына чагыштырмасын өйрәнә.

**Сфрагистика** — мөһерләр турындагы фән.

**Геральдика** — герблар турындагы фән.

**Археология** кешелекнең тарихи узганын матди чыганаклар буенча өйрәнә.

**Генеалогия** гаиләләр һәм туганлык элементләре мәсьәләләре, шәҗәрәләр төзү белән шөгыльләнә.

**Ономастика** — атамаларның килеп чыгышын;

**дипломатика** — актлар һәм рәсми документларның эчтәлеген;

**эпиграфика** — таш һәм металл өслекләрдәге язуларны;

**кодикология** — китап күчереп язучыларның социаль һәм һөнәри составын, китапларның таралу юлларын;

**бонистика** кәгазь акчалар тарихын өйрәнә.

**Нумизматика** тимер акчалар, алардагы язулар, акча әйләнеше белән шөгыльләнә.

**Тарихи география** борынгы кешеләрнең кайларда яшәве, борынгы дәүләтләрнең чикләре үзгәрү географиясе, борынгы шәһәрләрнең кайларда барлыкка килүе турында хәбәр итә.

Хәзер без аларның кайберләре белән якыннанрак танышырбыз.

**1. Палеография буенча бирем:**

**Кроссворд**




**Горизонталь буенча:**

1.Чөй язу белән нинди материалга язганнар?

2. Бүген аннан затлы күлмәкләр тегәләр, кайчандыр Борынгы Шәрык илләрендә аңа тушь белән язганнар.

3. Бозау тиресеннән ясалган язу материалы.

4. Иң борынгы һәм нык язу материалы.

5. Палеграфларның өйрәнү объекты.

**Вертикаль буенча:**

6. Иң киң таралган язу материалы.

**Җаваплар. 1.** Балчык. **2.** Ефәк, **3.** Пергамент. **4.** Таш. **5.** Кульязма. **6.** Кәгазь.

**2. Хронология буенча бирем.**

**Укытучы.** Сез инде төрле дәүләтләрдә еллар исәбен төрлечә алып баруларын беләсез. Борынгы Мисырда һәр фараоннан башлап яңа исәп башлаганнар. Борынгы Римда ел исәбе Римга нигез салганнан башланган. Борынгы греклар еллар исәбен Олимпия уеннары буенча алып барганнар. Русьта ел исәбен XVII гасыр ахырына кадәр дөнья яратылганнан башлап алып барганнар. Без сезнең белән ел исәбен Иисус Христос туган көннән алып барабыз. Әйдәгез, төрле ел исәбен алып бару системаларын тәңгәлләштереп карыйк.

● Хәзер ничәнче ел? *(2012 ел.)* Хәзер ничәнче гасыр? *(XXI гасыр.)*

● Римга ничәнче елда нигез салынган? *(Б.э.к.753 елда.)* Ул ничәнче гасыр була?

● Римга ничә яшь? *(2012 + 753 = 2765 ел.)*

● Иисус Христосның Рим хакимияте астында булган Фалыстенда тууы билгеле. Ул Римга нигез салынып ничә ел узгач туган? *(753 ел.)*

● Беренче Олимпия уеннары ничәнче елда уза? *(Б.э.к. 776 елда.)*

● Римга нигез салыну вакытына кадәр Олимпия ярышлары ничә тапкыр узган? *(776 – 753) : 4 = 5 тапкыр (калдык 3 ел.)*

● Русьта христиан дине 988 елда кабул ителә. Әлеге вакыйга Римга нигез салынганнан соң ничә ел үткәч була? *(753 + 988 = 1741 ел.)*

**3. Геральдика буенча бирем.**

● Әлеге рәсемнәрдә Казан губернасының кайсы өяз шәһәрләре герблары тасвирланган? *(Казан губернасына караган шәһәр герблары рәсемнәрен «Татарская энциклопедия»нең II томыннан (95 бит) табарга мөмкин.)* Һәркайсындагы сурәт нәрсәне аңлата?



*(Спас, Лаеш һәм Мамадыш шәһәрләре герблары. Соңгысы — Мамадыш өязенеке. Аның тасвирламасы болай булган: яшел кыр рәвешендәге җирлектә ике көмеш урак уртасына урнаштырылган алтын башаклар бу төбәкнең икмәккә бай булуына ишарә. Щитның югары өлешендәге ак кырда урнаштырылган алтын таҗ кидерелгән кызыл канатлы кара елан Мамадышның Казан губернасына керүен белдерә.)*

Ә Татарстан, Россия герблары нәрсәне символлаштыра?



**Татарстан гербы**



**Россия Федерациясе гербы.**

**4. Генеалогия буенча бирем.**

Генеалогия шәҗәрәләр төзү белән дә шөгыльләнә. Шәҗәрә — *гарәпчә «агач»* дигән мәгънәгә ия. Ул агач ботаклары кебек тармакланып киткән нәсел тәртибен барларга, күзалларга ярдәм итә. Борынгылар безгә һәркем үзенең 7 буын бабасын белергә тиеш, дип васыять иткән. Тарихны, үз туганнарыңны онытмау — *саваплы эш.* Ә сез ничә буыныгызны беләсез? Әйдәгез, хәзер үз шәҗәрәгезне төзеп карагыз әле.

**5. *Ономастика* буенча бирем.**

**Укытучы.** Алтын базы, Хәлмәкәй, Караавыл, Шахта урамы, Аккош тавы, Кызыл яр, Имән күпер... Болар — безнең төбәк белән бәйле атамалар. Әйдәгез әле, аларның килеп чыгышлары һәм ни өчен шулай аталулары белән танышыйк. *(Укучылар әлеге атамаларга бәйле булган, үзләре белгән риваятьләрне сөйли. Бергәләп әлеге атамалар барлыкка килүнең фәнни версиясе дә тикшерелә.)*

**6. Метрология буенча бирем.**

**Укытучы.** Кечерәк кисемтәләрне бик борынгыдан бирле кеше гәүдәсенең кайбер өлешләренә бәйләп үлчәгәннәр. Бу — терсәктән бармак очларына кадәр кул озынлыгы. Бармаклар киңлеге, уч киңлеге, аяк табаны озынлыгы һ.б. Алар озынлык үлчәү берәмлекләренең иң борынгыларыннан санала.

Чыннан да, әгәр ераклыкны үлчәгәндә кешенең сизү органнары (күрү, ишетү) файдаланылса, иң гади көндәлек кирәк-яракны эшләгәндә (хезмәт кораллары, торак, кием-салым) кеше үз гәүдәсе өлешләре — кул, аяк табаны, бармаклары озынлыгы һ.б. белән үлчәп караган.

Хәзер дә әле төрле әйберләрнең һәм суның биеклеген, тирәнлеген билгеләгәндә үзенә бер төрле зурлыклар киң кулланыла: «билдән», «күкрәктән» һ.б., ягъни кешенең буе үлчәнә торган объект белән чагыштырып карала. «кеше буе» (агач), «тездән су» һ.б.

Татарларда борын-борыннан килгән түбәндәге үлчәү берәмлекләре бар:

- **бер кул (беләк) буе** — кул озынлыгы (бармак очларыннан иңбашына кадәр ара);
- **терсәк буе** — терсәк озынлыгы (терсәк буыныннан кулга кадәргә ара);
- **тулы терсәк** — терсәк буыныннан урта бармак очына кадәрге ара;
- **зур тулы терсәк** — терсәк буыныннан урта бармак очына кадәрге араны ике тапкыр кабатлау;
- **ким терсәк** — терсәк буыныннан йодрыклаган кулга кадәрге ара;
- **кул яссуы** — уч яки биш бармак киңлеге;
- **бер яссу, ике яссу** — бер уч, ике уч киңлеге;
- **бер илле, бармак иллесе** — бармак калынлыгы;
- **ике илле, өч илле, дүрт илле, биш илле** — бер, ике, өч, дүрт, биш бармак калынлыгы;
- **бер яссу да, бер илле** — уч киңлеге һәм бер бармак калынлыгы һ.б.;
- **бармак буе** — бармак озынлыгы;
- **ярты бармак озынлыгы** — ярты бармак озынлыгы.

Шәрык илләрендә тагын **«патша терсәге»** дигән *берәмлек тә* кулланылган. Ул шушы дәүләтнең эчке сәүдәсендә рәсми танылган озынлык үлчәү берәмлеге булган.

Борынгы Русьта **чакрым** (верста) озынлыкны үлчәү өчен кулланылган берәмлекләр арасында иң зурысы булган. Ул 500 сажинны үз эченә алган.

Әгәр дә сажинның кеше буеннан бәйле икәнен исәпкә алсак, һәр кешенең үз сажины килеп чыга. (Бер сажин — як-якка җәелгән кулларның бармак очларындагы ара, якынча 2,13 *м*.) Ә мондый үлчәү системасы белән исәпләү шактый уңайсыз булган. Шуңа да кешеләр метр, сантиметр, дециметр белән үлчәүгә күчкән, алар кешенең кул озынлыгыннан бәйле түгел бит. Әйдәгез, бер чакрымны метрларда исәпләп карыйк. *(500 · 2,13 = 1065 м = = 1,065 км.)*

**7. Нумизматика буенча бирем.**

**Динар** — гарәпләрдә акча берәмлеге. Гарәпчә «динар» римлыларның көмеш акчалары — «денарий»дан килеп чыккан (денарий — *латинча «унарлап»* дигәнне аңлата). Билгеле булганча, динар — мөселман Шәрыгында XII гасырда гарәпләр тарафыннан кертелгән алтын тәңкә. Динар исәпләү берәмлеге булып торган һәм акча системасында алтын, көмешнең күләм чагыштырмасын күрсәткән.

Төркиләр бакыр акчаларны **пул** дип гомумиләштереп әйткән. Аларның авырлыгына да, кыйммәтенә дә өстенлек бирелмәгән. Ул теге яки бу акчаның бакыр булуын аңлаткан. Моны язма чыганаклар да раслый. Бакыр акча исеме буларак, «пул» сүзе Себердә һәм Иранда кулланыла.

**Тәңкә** (»тәңгерек» — түгәрәк дигән сүздән) дип XIV — XVI гасырларда Идел буе халыклары арасында таралган төп көмеш акчаны атаганнар. Авырлыгы ягыннан алар һәрчак үзгәреп торган. Урта Азиядә, мәсәлән, XX гасырга кадәр 3,25 *г* лы көмеш акчаны тәңкә дип атаганнар. Руська азрак үзгәртелгән рәвештә («деньга») вак акча мәгънәсендә кереп киткән.

**Алтын** — болгарларда акча исәпләү берәмлеге булып йөргән. Ул русларда да шундый ук мәгънәгә ия булган. Алтын — 6 теньгага (Мәскәү акчасы) һәм 3 нократка (тиенгә) бәрабәр. Йөз алтын өч сумга тигез булган.

**Көмеш тиен**нәр өчен «тиен», «нократ» терминнары кулланылган. Нократ — фарсыча «көмеш» дигән сүз.

- Рус акча берәмлеге — «рубль» һәм «копейка»ның килеп чыгышын аңлатыгыз.
- «Сезнең авылның кызлары

Бишесе бер барнаул», — дип шаяртып җырлаганда нәрсәне күздә тотканнар? *(«Барнаул» — русларның өч тиенлек бакыр акчасы.)*

**Кичәне йомгаклау.**

**Укытучы.** Ә хәзер, әйдәгез, нәтиҗәләр ясыйк:

— Без бүген нәрсәләр турында сөйләштек?

— Үзегез өчен нинди яңалыклар ачтыгыз?

— Кайсы фәннәр сезне ныграк кызыксындырды?

— Тарих буенча тагын яңа фактлар беләсегез киләме?

— Тарих фәненә карата карашыгыз үзгәрдеме?

Шуның белән бүгенге кичәбез тәмам. Активлыгыгыз өчен барыгызга да зур рәхмәт.